

# Белем сыйфатын күтәрү – заман таләбе

*Борһаниев Ринат Габдрахманович, Әгерҗе районы Исәнбай гомуми урта белем бирү мәктәбе директоры.*

Исәнбай урта мәктәбе 1897 елда ачылган. 2017елда мәктәп 120 еллык юбилеен каршы ала. Бүгенге көндә нык, төзек, якты бинага урнашкан бу уку йортында 90 укучы гомуми белем ала, 30 мәктәпкәчә яшьтәге бала тәрбияләнә. Барлык предметлар да татар телендә укытыла. Мәктәбебез педагогик коллективы сыйфатлы белем бирү, дәүләт белем бирү стандарты таләпләрен үтәү, укыту-тәрбия процессын камилләштерү буенча максатчан эш алып бара. Бу эшләрнең нәтиҗәсе буларак, безнең мәктәп 2013 нче һәм 2017 елларда Татарстан Республикасының иң яхшы 100 мәктәп исемлегенә керде. Ә 2014 һәм 2017 елларда районның иң яхшы мәктәп конкурсында җиңеп чыкты.

Соңгы елларда мәгариф системасына яңалыклар әледән-әле кертелеп кенә тора. Бу үзгәрешләр балалар бакчаларындагы сабыйлардан алып, чыгарылыш сыйныф укучыларына кадәр кагыла. Белем бирүнең сыйфатын күтәрүгә ил күләмендә зур әһәмият бирелә. Дөрестән дә, мәгариф системасына федераль белем бирү стандартлары кертелү укытучылар һәм тәрбиячеләр алдына яңа бурычлар куйды. Моңа кадәр яшәп килгән гадәти дәресләр, тәрбия чаралары белән генә чикләнеп калмыйча, яңача эш итүне таләп итә. Укучыларга белем бирүне генә түгел, ә аларны белем алырга, алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтүне төп максат итеп куя. Бу исә белем бирүнең яңа алымнарын һәм методларын кулланып эш итүне, бүгенге көн таләпләренә җавап биргән дәресләр һәм тәрбия чараларын оештыруны таләп итә. Укучыларны хезмәткә, тормышка әзерләү аларга сыйфатлы белем бирү – безнең төп бурычыбыз. Мәктәбебездә сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү өчен бөтен мөмкинлекләр бар дип саныйм. Уку программалары камилләшә, алдынгы педагогик технологияләр кертелә, матди-техник база яхшыра. Мәгълүм булганча, мәгариф системасы үсеше, белем сыйфаты укытучының һөнәри гыйлеменә ни дәрәҗәдә ия булуына бәйле. Безнең мәктәптә үз эшләренең чын остасы тәҗрибәле укытучылар белем бирә. 15 укытучының 7 се югары категорияле,7 се беренче категорияле. Соңгы елларда 5 укытучы (Садыкова Г.З., Борһаниева Ә.Р., Хуҗина Г.Р., Зәйнуллина Г.З., Симаков Ф.Ф.) “Безнең иң яхшы укытучы”, ә математика укытучысы Борһаниева Ә.Р., 2007 һәм 2014 елларда “Мәгариф” өстенлекле илкүләм проекты кысаларында үткәрелгән бәйгеләрдә 2 мәртәбә җиңү яулап Россия Президенты грантына ия булды. 2014-2015 нче уку елында Исәнбай урта мәктәп музее (җитәкчесе Зәйнуллина Г.З.) Бөек җиңүнең 70 еллыгына багышланган “Иң яхшы мәктәп музее” Республика конкурсында җиңеп чыгып I дәрәҗәдәге дипломга лаек булды. Технология укытучысы Симаков Ф.Ф. 2016 нче елды “Укытучы-мастер”, татар теле укытучысы Хузина Г,Р. 2016 һәм 2017 нче елларда“Укытучы-эксперт” бәйгесендә җиңү яулады.

Милли мәгариф системасының иң мөһим күрсәткече исә, балаларга ана телендә белем һәм тәрбия бирү өчен шартлар тудыру. Балалар белән эшләүнең заманча һәм яңа алымнары кулланып татар мәктәпләрендә дә уңышларга ирешеп була һәм безнең мәктәп тотрыклы рәвештә алдынгы позицияләрне били. Татар телендә сыйфатлы белем биреп яки алып булганын чыгарылыш сыйныф укучылары да раслады. Бердәм, дус коллективның хезмәт уңышлары да шактый: укучыларыбыз елдан-ел бердәм дәүләт имтиханнарында югары күрсәткечләр белән сөендерәләр. 2015 нче елда 9 нчы сыйныфлар БДИ нәтиҗәләре

буенча республикада рус теленнән беренче, математикадан 2 урынны яуладылар. 2016-2017 нче уку елының БДИ нәтиҗәләре: математикадан уртача балл 73,6, рус теленнән-81,4, химиядән -72,6, физикадан -68, биологиядән -77, җәмгыять белеменнән -69.
Мәктәптә сәләтле балаларны ачыклауга, алар белән нәтиҗәле эшләүгә зур игътибар бирелә. Укучылар республика, регионара, россия күләмендә үткәрелә торган төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда, олимпиадаларда төрле дәрәҗәдәге уңышларга ирешәләр.

Соңгы 3 елда технология фәненнән, татар теленнән һәм әдәбиятыннан республика күләмендә олимпиадаларда катнашып призлы урыннар яулыйбыз.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы 2017 елда иң яхшы мәктәпләр рейтингын тәкъдим итте. Рейтинг башлыча БДИ күрсәткечләренә һәм олимпиадаларда җиңүчеләр санына нигезләнеп төзелгән.Исәнбай урта мәктәбе – бу рейтингта сигезенче урында. Без моның белән горурланабыз.
Әлбәттә, тәрбия һәм белем бирүнең нигезен тәшкил иткән рухи кыйммәтләр дә бар. Аларны сакларга тырышырга кирәк. Туган телгә һәм туган якка мәхәббәт кебек кыйммәтләр бик мөһим. Үткәнен хөрмәт итүче, мөстәкыйльлеккә әзер һәм киләчәгенә җаваплы караучы шәхес үстерүнең нигезе ул.

Хөкүмәтебез хәзер педагогик вузларга максатчан кабул итү уздыра. Быел Әгерҗе районы чыгарылыш укучылар арасында да андый бәйге оештырылды һәм шунсы куанычлы безнең мәктәп укучылары Хакимов Илнур, Газизов Рамис БДИ нәтиҗәләре буенча сайлап алынды, алар физика-математика укытучысы булырга ай саен 15 мең сум стипендия алып Алабуга дәүләт педагогия университетында белем алачаклар.

Мәктәптә алган белемнәрнең югары сыйфатлы булуы илнең гомуми культура дәрәҗәсен билгели. Эш приоритетларын дөрес билгели алган, фикере тирән, карашы заманча, үз өстендә бертуктаусыз эшләргә әзер мәктәп җитәкчеләре генә республика һәм илебез мәгарифен лаеклы югарылыкка күтәрергә мөмкин.